**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2016 ел, 15 апрель | № 228

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль учреждениеләр күрсәтә (башкара) һәм бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (эшләрнең) якынча исемлеген раслау турында» 2015 ел, 05 сентябрь, 638 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында муниципаль учреждениеләр күрсәтә (башкара) һәм бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (эшләрнең) якынча исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль учреждениеләр күрсәтә (башкара) һәм бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (эшләрнең) якынча исемлеген раслау турында» 2015 ел, 05 сентябрь, 638 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында муниципаль учреждениеләр күрсәтә (башкара) һәм бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (эшләрнең) якынча исемлегенә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 30 декабрь, 1020 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (теркәлгән).

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль учреждениеләр күрсәтә (башкара) һәм бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (эшләрнең) якынча исемлеген раслау турында» 2015 ел, 05 сентябрь, 638 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында муниципаль учреждениеләр күрсәтә (башкара) һәм бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (эшләрнең) якынча исемлеге

(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 30 декабрь, 1020 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) гамәлдә булуны 2017 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

3. Бу карарның 1 пункты 2017 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков